**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

№2 29 октябрь 2025 ел

2026 елда Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районы Әлкәй авыл
җирлеге Әлкәй торак пунктында гражданнардан
үзара салым кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 20.03.2025 ел №33-ФЗ Федераль законның 45,69 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районының Әлкәй авыл җирлеге Әлкәй торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2026 елда 1 төркем инвалидлар, көндезг уку формасы буенча белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциягә юнәлтелгән гаилә әгъзасы тупланган гаиләләрдән тыш, Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Әлкәй авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 600 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүг буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Нагорный тыкрыгы буйлап вак таш сатып алу, төяү, ташу, салу);
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү эм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итү (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту, материаллар, җайланмалар сатып алу, торбаларны алмаштыру).;
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (стелла сатып алу һәм урнаштыру, үлән чабу, юлларны кардан чистарту).

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга: http//aznakayevo.tatar.ru.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Әлкәй авыл җирлеге башлыгы А.Н.Арсланов